| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2024 г. Агрыз № 43-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары контроль-хисап органы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"гы 26.10.2022 елның 20-8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләре үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 28.03.2018 ел, № 182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 25.09.2024 ел, № 829 карары нигезендә, Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары контроль-хисап органы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы 11.07.2024 № 38-6 карары редакциясендә) кушымтада бирелә торган үзгәрешләрне кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе ,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советы 26.12.2024 № ____
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары контроль-хисап органы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"гы 26.10.2022 елның 20-8 номерлы карарына үзгәрешләр

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
" Әгерҗе муниципаль районы Башлыгына, Әгерҗе муниципаль районы башлыгы урынбасарына, Әгерҗе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенә айлык акчалата түләү күләмендә билгеләргә.:

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 37036 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 33333 |
| Контроль-хисап палатасы Рәисе | 33333 |

1.2. Карарның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органында билгән муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә вазыйфаи окладны:

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 36374 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 32737 |
| Совет аппараты җитәкчесе | 33017 |
| Башкарма комитетның эшләр идарәчесе | 30639 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 32597 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 29939 |
| Советның, башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең башка органының бүлек башлыгы | 25462 |
| Совет, Башкарма комитет һәм җирле үзидарәнең башка органы бүлеге башлыгы урынбасары | 22245 |
| Башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең башка органының сектор мөдире | 20566 |

| | |
|---|---|
| Район башлыгы ярдәмчесе, район Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | 22245 |
| Советның, башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең башка органының баш белгече | 19726 |
| Советның, башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең башка органының әйдәп баручы белгече | 18327 |